# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Арча шәһәре" һәм "Төбәк-Чокырча авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләрен үзгәртеп кору, Арча һәм Саба муниципаль районнары һәм аларның составына керүче аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Арча муниципаль районы составына керүче "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеген әлеге җирлек халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы һәм "Төбәк-Чокырча авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген әлеге җирлек халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә әлеге җирлекләрне "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенә (алга таба – "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлеге) берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга.

**2 статья**

1. "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлеге беренче чакырылыш вәкиллекле органының һәм башлыгының вәкаләтләре вакытын биш ел дип билгеләргә.

2. "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы унбиш депутаттан тора дип билгеләргә.

3. "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларга әзерлек һәм аларны үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасы турында "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган карарда башкасы билгеләнмәсә, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлеге башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан беренче утырышта яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

"Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, әгәр аны сайлау өчен вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, әлеге муниципаль берәмлек башлыгы итеп сайланган дип исәпләнә.

"Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлеге башлыгы сайланганчы, әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның иң өлкән яшьтәге депутаты ача һәм алып бара;

2) "Арча шәһәре" яңа төзелгән муниципаль берәмлегенең сайлап куелган башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы "Курса-Почмак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең территорияләре чикләрен "Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**5 статья**

Акчишмә авылында яшәүче халыкның тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы, шулай ук Хәтнә һәм Наратлык авылларында яшәүче халыкның гражданнар җыеннарында белдерелгән ризалыгы нигезендә, "Ташкичү авыл җирлеге", "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары фикерен исәпкә алып, әлеге Закон нигезендә Арча муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртергә:

1) "Ташкичү авыл җирлеген" аның составына Шушмабаш авыл җирлегенең Акчишмә, Наратлык һәм Хәтнә авылларын, янәшәләрендәге территорияләрен дә кертү юлы белән;

2) "Шушмабаш авыл җирлеген" аның составына керүче Акчишмә, Наратлык һәм Хәтнә авылларын, янәшәләрендәге территорияләрен дә Ташкичү авыл җирлегенә кертү юлы белән.

**6 статья**

"Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда "Айван" сүзеннән соң ", Төбәк-Чокырча" сүзен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Ташкичү авыл җирлеге: Ашытбаш (административ үзәк), Ташкичү, Мәмсә, Хәтнә, Акчишмә, Кысна, Наратлык авыллары;";

б) егерме дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;


в) егерме тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Шушмабаш авыл җирлеге: Шушмабаш (административ үзәк), Шекә, Илдус, Үгез-Елга авыллары;";

3) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 13(12)-8(13) | - Марий Эл Республикасы |
| 8(13)-24 (50) | - Балтач муниципаль районы |
| 24(50)-58(49) | - Саба муниципаль районы |
| 58(49)-66(48) | - Теләче муниципаль районы |
| 66(48)-64(46) | - Питрәч муниципаль районы |
| 64(46)-53(47) | - Биектау муниципаль районы |
| 53(47)-13(12) | - Әтнә муниципаль районы |

"Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Арча шәһәре |
| 2 | Апаз авыл җирлеге |
| 3 | Венета авыл җирлеге |
| 4 | Казанбаш авыл җирлеге |
| 5 | Кәче авыл җирлеге |
| 6 | Кушлавыч авыл җирлеге |
| 7 | Күпербаш авыл җирлеге |
| 8 | Наласа авыл җирлеге |
| 9 | Яңа Кенәр авыл җирлеге |
| 10 | Яңа Кишет авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Кырлай авыл җирлеге |
| 12 | Носы авыл җирлеге |
| 13 | Сеҗе авыл җирлеге |
| 14 | Сикертән авыл җирлеге |
| 15 | Курса-Почмак авыл җирлеге |
| 16 | Урта Аты авыл җирлеге |
| 17 | Урта Курса авыл җирлеге |
| 18 | Урта Пошалым авыл җирлеге |
| 19 | Иске Ашыт авыл җирлеге |
| 20 | Иске Кырлай авыл җирлеге |
| 21 | Иске Чүриле авыл җирлеге |
| 22 | Сөрде авыл җирлеге |
| 23 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 24 | Үрнәк авыл җирлеге |
| 25 | Утар Аты авыл җирлеге |
| 26 | Өчиле авыл җирлеге |
| 27 | Шурабаш авыл җирлеге |
| 28 | Шушмабаш авыл җирлеге |
| 29 | Яңасала авыл җирлеге"; |

4) 2 нче кушымтада:

а) уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"– алга таба чик "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Курса участок урманчылыгындагы урман массивының

көнбатышы буйлап төньяк юнәлештә әлеге урман массивының төньяк ноктасына кадәр дәвам итә, шуннан соң аның төньягы буенча 871 нче километр тукталыш платформасыннан 40 м көньяк-көнчыгышта тимер юл киселешенә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,98 км әлеге урманчылыктагы 149, 144, 139 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 1,65 км әлеге урманчылыктагы 139, 140, 141 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 600 м 141 нче урман кварталы буйлап, 120 м әлеге урманчылыктагы 140 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 155 м Курса тимер юл разъезды поселогы чиге буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,06 км әлеге урманчылыктагы 141 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м әлеге урманчылыктагы 135 нче урман кварталы буйлап, 30 м әлеге урманчылыктагы 136 нчы урман кварталы буйлап урман питомнигына кадәр уза, аны көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, шуннан соң төньякка таба 36 м чираттагы урман питомнигына кадәр уза, аны көньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары төньяк-көнбатышка таба 190 м әлеге урманчылыктагы 136 нчы урман кварталы буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м әлеге урманчылыктагы 135 нче урман кварталы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,3 км әлеге урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары көнбатышка таба 1,64 км әлеге урманчылыктагы 135, 134, 133 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза;";

б) кырык икенче һәм кырык өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

5) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Арча муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Арча муниципаль районының**
**"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе**
**чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге Кәче, Күпербаш, Наласа, Урта Курса, Яңасала авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.

**Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Күпербаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш һәм Наласа авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Бирәзә авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньяк-көнчыгыш юнәлештә кибеп баручы инеш агымы буенча уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 470 м көньяк-көнчыгышка таба, 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньякка таба, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" автомобиль юлын кисеп үтеп, 300 м көнчыгышка таба бара, аннары 140 м көньякка таба әлеге автомобиль юлының көнчыгыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казан – Малмыж автомобиль юлы чатына кадәр бара, аннары "Казан – Малмыж" – Күпербаш автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км бара, шуннан соң, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, 74 м көнчыгышка таба, 490 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 137 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 810 м төньяк-көнчыгышка таба, 306 м көнчыгышка таба, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба зиратка кадәр, шуннан соң шушы зират чиге буйлап 198 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 290 м төньяк-көнбатышка таба, 9 м көньяк-көнбатышка таба автомобиль юлына кадәр, шушы автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 5 м көньяк-көнчыгышка таба, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, шул ук юнәлештә 36 м бара. Шуннан соң чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 120 м көньякка таба, 145 м көньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнбатышка таба, 25 м көнбатышка таба, 261 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м көнбатышка таба, 376 м көньяк-көнбатышка таба, 5 м көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары торф чыгару урыннарының кырые буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, дамбаны кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км дамба буйлап "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш һәм Урта Курса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Төбәк-Чокырча авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Урта Курса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Урта Курса авыл җирлеге һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Алан авылыннан 4,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасыннан алып 3,0 км көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 520 м төньяк-көнбатыш юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап туп-туры

уза, 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,5 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, шул ук юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 220 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм канауны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 40 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап канауга кадәр бара, шуннан соң канау буйлап 60 м төньякка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 210 м көньяк-көнчыгышка таба, 310 м төньяк-көнчыгышка таба, 210 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 250 м төньякка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 340 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 60 м буаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза. Шуннан соң чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 280 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньякка таба, 150 м көнчыгышка таба, 100 м көньякка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 140 м төньякка таба, 270 м төньяк-көнчыгышка таба, 30 м төньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба куаклыкка кадәр бара, шуннан соң куаклык буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, 120 м төньяк-көнбатышка таба, 60 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 620 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньякка таба, 110 м көнбатышка таба, 120 м көньяк-көнбатышка таба, Кисмәс елгасын кисеп үтеп, 130 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 570 м көньяк-көнбатышка таба, 290 м төньяк-көнбатышка таба чокырга кадәр бара, аннары 510 м чокырның көньягыннан бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, 430 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Арча балык хуҗалыгы буасына кадәр бара, аннары, Арча балык хуҗалыгы буасын төньяк чигеннән әйләнеп узып, гомуми юнәлештә 1,9 км көнбатышка таба 47 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Теләче муниципаль районы белән чиктәш җирдә 57 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чиге буйлап "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Яңасала авыл җирлеге һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 5,3 км көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Яңасала авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,3 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 210 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 210 м куаклык буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 190 м куаклык буйлап, "Арча – Теләче" – Яңасала автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аңа икенче инеш койган җиргә кадәр 600 м уза, аннары шушы инеш агымы буенча өскә таба 350 м бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,0 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, чокырны һәм Арча – Каенсар автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Саба урманчылыгы" Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң шушы урман кварталын көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кәче һәм Яңасала авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Якты Көн авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр әйләнеп уза.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Кәче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатыш юнәлештә 2,2 км "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 1, 2 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 1,3 км шушы урманчылыктагы 1 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 1,0 км Арча – Якты Көн автомобиль юлы буендагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 1,2 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инеш белән кисешкән җиргә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 450 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 160 м төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 230 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 470 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап Арча – Чулпан автомобиль юлына кадәр, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 750 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары шушы елга агымы буенча 2,1 км өскә таба "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кәче һәм Наласа авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәче авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Наласа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып Казансу елгасы агымы буенча өскә таба 1,7 км шушы елгага инеш койган җиргә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 56 м көнбатышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 40 м көньяк-көнбатышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 164 м көнбатышка таба, 136 м төньякка таба, 5 м көнбатышка таба, 361 м төньякка таба, аннары автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 68 м төньяк-көнчыгышка таба бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 16 м шул ук юнәлештә, шуннан соң автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш ягы буенча 147 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары Зур Бирәзә авылының көнбатыш чиге буйлап 132 м төньяк-көнчыгышка таба, 115 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына кадәр, шуннан соң шушы автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягы буенча 92 м төньяк-көнбатышка таба, аннары, шушы автомобиль юлын кисеп үтеп, 14 м төньяк-көнчыгышка таба, әлеге автомобиль юлының көнчыгыш ягы буйлап 506 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң урман полосасы буйлап 130 м көнчыгышка таба, 46 м көньяк-көнчыгышка таба, 7 м төньякка таба, 69 м көнчыгышка таба, 13 м көньякка таба, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 34 м көнчыгышка таба, 47 м көньякка таба, 97 м көньяк-көнчыгышка таба, 196 м көньяк-көнбатышка таба, 68 м көньяк-көнчыгышка таба инешкә кадәр, шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,61 км уза, аннары 123 м

төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча 950 м өскә таба 48 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

6) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Носы," сүзеннән соң "Ташкичү," сүзен өстәргә;

б) бишенче абзацта "Шушмабаш" сүзен "Ташкичү" сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Апаз авыл җирлеге чиге Шушмабаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Апаз, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгыштa урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 770 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасы буйлап бара, аннары 1,3 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Апаз – Шушмабаш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап профильле автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 250 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Апаз, Носы һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үгез-Елга авылыннан 400 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Апаз авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 1,4 км төньякка таба "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 67, 69 нчы урман кварталлары чиге буйлап уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба озын чокыр буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 300 м чокыр буйлап уза, шуннан соң 90 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

7) 7 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Төбәк-Чокырча," сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кәче авыл җирлеге чиге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кәче һәм Яңасала авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Якты Көн авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатыш юнәлештә 2,2 км "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Ленин участок урманчылыгындагы 1, 2 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 1,3 км шушы урманчылыктагы 1 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 1,0 км Арча – Якты Көн автомобиль юлы буендагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 1,2 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инеш белән кисешкән җиргә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 450 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 160 м төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 230 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 470 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап Арча – Чулпан автомобиль юлына кадәр, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 750 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары шушы елга агымы буенча 2,1 км өскә таба 50 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 9 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта ", Төбәк-Чокырча" сүзен төшереп калдырырга;

б) җиденче абзацта "Күпербаш, Урта Курса һәм Төбәк-Чокырча авыл җирлекләре" сүзләрен "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш һәм Урта Курса авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

в) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Күпербаш авыл җирлеге чиге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш һәм Наласа авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Бирәзә авылыннан 750 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньяк-көнчыгыш юнәлештә кибеп баручы инеш агымы буенча уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 470 м көньяк-көнчыгышка таба, 650 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньякка таба, "Арча – Марий Эл Республикасы чиге" автомобиль юлын кисеп үтеп, 300 м көнчыгышка таба бара, аннары 140 м көньякка таба әлеге автомобиль юлының көнчыгыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казан – Малмыж автомобиль юлы чатына кадәр бара, аннары "Казан – Малмыж" – Күпербаш автомобиль юлының төньяк-көнбатыш ягындагы авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км бара, шуннан соң, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, 74 м көнчыгышка таба, 490 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 137 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 810 м төньяк-көнчыгышка таба, 306 м көнчыгышка таба, 550 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба зиратка кадәр, шуннан соң шушы зират чиге

буйлап 198 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 290 м төньяк-көнбатышка таба, 9 м көньяк-көнбатышка таба автомобиль юлына кадәр, шушы автомобиль юлының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап 5 м көньяк-көнчыгышка таба, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, шул ук юнәлештә 36 м бара. Шуннан соң чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 120 м көньякка таба, 145 м көньяк-көнчыгышка таба, 163 м көньяк-көнбатышка таба, 25 м көнбатышка таба, 261 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м көнбатышка таба, 376 м көньяк-көнбатышка таба, 5 м көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары торф чыгару урыннарының кырые буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, дамбаны кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км дамба буйлап 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

9) 13 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Өчиле һәм Шушмабаш авыл җирлекләре" сүзләрен "һәм Өчиле авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Кырлай авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кишет, Яңа Кырлай һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Симетбаш авылыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары 2,0 км шушы урманчылыктагы 63, 60 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң 2,7 км көнчыгыш юнәлештә "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 60, 61, 62 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 390 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньякка таба борыла һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 160 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 230 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 620 м Яңа Кырлай, Урта Пошалым һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

10) 17 нче кушымтадагы тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 19 нчы кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Урта Курса авыл җирлеге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш, Курса-Почмак авыл җирлекләре, Саба һәм Теләче муниципаль районнары белән чиктәш.";

б) алтынчы абзацта "Урта Курса, Төбәк-Чокырча авыл җирлекләре" сүзләрен "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Урта Курса авыл җирлеге" сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Урта Курса авыл җирлеге чиге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 57 нче тоташу ноктасыннан алып 3,0 км көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 520 м төньяк-көнбатыш юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап туп-туры уза, 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,5 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, шул ук юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 220 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм канауны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 40 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап канауга кадәр бара, шуннан соң канау буйлап 60 м төньякка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 210 м көньяк-көнчыгышка таба, 310 м төньяк-көнчыгышка таба, 210 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 250 м төньякка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 340 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 60 м буаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза. Шуннан соң чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 280 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньякка таба, 150 м көнчыгышка таба, 100 м көньякка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 140 м төньякка таба, 270 м төньяк-көнчыгышка таба, 30 м төньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба куаклыкка кадәр бара, шуннан соң куаклык буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, 120 м төньяк-көнбатышка таба, 60 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 620 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньякка таба, 110 м көнбатышка таба, 120 м көньяк-көнбатышка таба, Кисмәс елгасын кисеп үтеп, 130 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 570 м көньяк-көнбатышка таба, 290 м төньяк-көнбатышка таба чокырга кадәр бара, аннары 510 м чокырның көньягыннан бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, 430 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Арча балык хуҗалыгы буасына кадәр бара, аннары, Арча балык хуҗалыгы буасын төньяк чигеннән әйләнеп узып, гомуми юнәлештә 1,9 км көнбатышка таба "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Күпербаш һәм Урта Курса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Төбәк-Чокырча авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

12) 20 нче кушымтадагы икенче, дүртенче, сигезенче һәм тугызынчы абзацларда "Шушмабаш" сүзен "Ташкичү" сүзенә алмаштырырга;

13) 25 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Ташкичү авыл җирлеге Апаз, Яңа Кенәр, Яңа Кишет, Яңа Кырлай, Иске Ашыт, Урта Пошалым, Шушмабаш авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы белән чиктәш.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Ташкичү авыл җирлеге чиге Яңа Кырлай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары 2,0 км шушы урманчылыктагы 63, 60 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң 2,7 км көнчыгыш юнәлештә "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 60, 61, 62 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 390 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньякка таба борыла һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 160 м, 230 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап һәм 620 м көнчыгыш чиге буйлап Яңа Кырлай, Урта Пошалым һәм Ташкичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Пионер авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Ташкичү авыл җирлеге чиге Урта Пошалым авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып 170 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 830 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасы буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр 260 м уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 89, 81, 76 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 3,3 км Урта Пошалым, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Ташкичү авыл җирлеге чиге Балтач муниципаль районы белән чиктәш җирдә Апаз, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Балтач муниципаль районы чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Арча муниципаль районы чикләре буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ташкичү авыл җирлеге чиге Апаз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә 1,4 км төньякка таба "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 67, 69 нчы урман кварталлары чиге буйлап уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнбатышка таба озын чокыр буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 300 м чокыр буйлап уза, шуннан соң 90 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап Апаз, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәтнә авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ташкичү авыл җирлеге чиге Шушмабаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып, Шекә – Мәмсә автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, озын чокырларны кисеп үтеп, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 540 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, "Ашытбаш – Шушмабаш – Карадуган" – Илдус автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 830 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 43, 42, 44, 45 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, төньяк чикләре буйлап 6,5 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6 м көньяк-көнчыгышка таба, 6 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 320 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 60 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

14) 26 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 31 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шушмабаш авыл җирлеге Апаз, Яңа Кенәр, Носы, Ташкичү авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.";

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шушмабаш авыл җирлеге чиге Апаз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Апаз, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хәтнә

авылыннан 2,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып 770 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасы буйлап бара, аннары 1,3 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, Апаз – Шушмабаш автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап профильле автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң 250 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) җиденче – тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шушмабаш авыл җирлеге чиге Ташкичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кенәр, Ташкичү һәм Шушмабаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шекә авылыннан 1,6 км көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып, Шекә – Мәмсә автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, озын чокырларны кисеп үтеп, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 540 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, "Ашытбаш – Шушмабаш – Карадуган" – Илдус автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 830 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, шуннан соң шушы урманчылыктагы 43, 42, 44, 45 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, төньяк чикләре буйлап 6,5 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6 м көньяк-көнчыгышка таба, 6 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 320 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 60 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

16) 32 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңасала авыл җирлеге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Венета, Кәче авыл җирлекләре һәм Теләче муниципаль районы белән чиктәш.";

б) бишенче абзацта "Кәче, Төбәк-Чокырча" сүзләрен "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кәче" сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңасала авыл җирлеге чиге "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге, Яңасала авыл җирлеге һәм Теләче муниципаль районы чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 5,3 км

көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,3 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 210 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 210 м куаклык буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 190 м куаклык буйлап, "Арча – Теләче" – Яңасала автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аңа икенче инеш койган җиргә кадәр 600 м уза, аннары шушы инеш агымы буенча өскә таба 350 м бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,0 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, чокырны һәм Арча – Каенсар автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ленин участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң шушы урман кварталын көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 56 нчы тоташу ноктасына кадәр әйләнеп уза.".

**7 статья**

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм аның составындагы "Мичән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**8 статья**

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *21(49) - 1(50)* | - Арча муниципаль районы |
| *1(50) - 2(51)* | - Балтач муниципаль районы |
| *2(51) - 39(52)* | - Кукмара муниципаль районы |
| *39(52) - 41(52а)* | - Теләче муниципаль районы |
| *41(52а) - 44(53)* | - Мамадыш муниципаль районы |
| *44(53) - 43(54)* | - Балык Бистәсе муниципаль районы |
| *43(54) - 21(49)* | - Теләче муниципаль районы |

"Саба муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Арташ авыл җирлеге |
| 3 | Олы Кибәче авыл җирлеге |
| 4 | Олы Нырты авыл җирлеге |
| 5 | Олы Шыңар авыл җирлеге |
| 6 | Югары Симет авыл җирлеге |
| 7 | Яулаштау авыл җирлеге |
| 8 | Эзмә авыл җирлеге |
| 9 | Иштуган авыл җирлеге |
| 10 | Килдебәк авыл җирлеге |
| 11 | Курсабаш авыл җирлеге |
| 12 | Мишә авыл җирлеге |
| 13 | Мичән авыл җирлеге |
| 14 | Түбән Шытсу авыл җирлеге |
| 15 | Сатыш авыл җирлеге |
| 16 | Иске Икшермә авыл җирлеге |
| 17 | Тимершык авыл җирлеге |
| 18 | Шәмәрдән авыл җирлеге |
| 19 | Шекше авыл җирлеге |
| 20 | Юлбат авыл җирлеге"; |


2) 2 нче кушымтада:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"– алга таба чик "Саба урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Курса участок урманчылыгындагы урман массивының көнбатышы буйлап төньяк юнәлештә әлеге урман массивының төньяк ноктасына кадәр дәвам итә, шуннан соң аның төньягы буенча 871 нче километр тукталыш платформасыннан 40 м көньяк-көнчыгышта тимер юл киселешенә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,98 км әлеге урманчылыктагы 149, 144, 139 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 1,65 км әлеге урманчылыктагы 139, 140, 141 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 600 м 141 нче урман кварталы буйлап, 120 м әлеге урманчылыктагы 140 нчы урман кварталының

«Арча шәһәре» һәм «Төбәк-Чокырча авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрен үзгәртеп кору, Арча һәм Саба муниципаль районнары һәм аларның составына керүче аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# «Арча муниципаль районы» һәм «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чиге участогы карта-схемасы




Шартлы билгеләр

А-Б Арча һәм Саба муниципаль районнарының чиктәш чикләре

җирлекләрнең чикләре

Арча муниципаль районы территориясе составына кертелүче территория

торак пункт

көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 155 м Курса тимер юл разъезды поселогы чиге буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,06 км әлеге урманчылыктагы 141 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м әлеге урманчылыктагы 135 нче урман кварталы буйлап, 30 м әлеге урманчылыктагы 136 нчы урман кварталы буйлап урман питомнигына кадәр уза, аны көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, шуннан соң төньякка таба 36 м чираттагы урман питомнигына кадәр уза, аны көньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары төньяк-көнбатышка таба 190 м әлеге урманчылыктагы 136 нчы урман кварталы буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м әлеге урманчылыктагы 135 нче урман кварталы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,3 км әлеге урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары көнбатышка таба 1,64 км әлеге урманчылыктагы 135, 134, 133 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза;";

б) утыз бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 нче кушымтадагы тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

**9 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 18-ТРЗ